**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» июль, 2021 ел № 420

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2021 елның 2 яртыеллыгына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен раслау турында

Россия Федерациясенең Торак коды нигезендә, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы тарафыннан, «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2021 елның 12 февралендәге 48 номерлы «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» Коммерцияле булмаган партнерлыгының хатына таянып, Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен максималь күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 439 724 сум

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1 832 376 сум

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 2 620 620 сум

1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 2 355 912 сум

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 3 141 216 сум

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 3 926 520 сум

1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 4 711 824 сум

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 19 016 сум

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 12 100 сум

1.2.3. Өч кешелек гаилә өчен - 10 372 сум

2. Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә

Питрәч муниципаль районы наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән максималь күләмнәрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1633605397